СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2024 елның «26» декабре Алабуга шәһәре № 402

Алабуга муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» 2023 елның 15 декабрендәге 301 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Алабуга муниципаль районындагы бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 83 һәм 86 статьясына таянып, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» 2023 елның 15 декабрендәге 301 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

*14 өлештә*

1 пунктта «3 945 178,0» саннарын «4 314 413,1» саннарына алмаштырырга;

2 пунктта «4 406 134,8» саннарын «4 782 110,5» саннарына алмаштырырга;

3 пунктта «460 956,8» саннарын «467 697,4» саннарына алмаштырырга;

*3 өлештә*

1 нче кушымтаның «2024 елга район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә.

2) 3 статьяда:

2 нче кушымтаның «2024 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының фаразлана торган керемнәре күләме» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә.

3) 5 статьяда:

3 нче кушымтаның «2024 елга Алабуга муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә;

4 нче кушымтаның «2024 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең

бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (АМР муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә;

5 нче кушымтаның «2024 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (АМР муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлү» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә;

Район бюджетының 2024 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме «67 848,2» санын «144 416» санына алмаштырыргаа;

әлеге статьяда расланган бюджет ассигнованиеләре составында резервланган, бюджет классификациясе бүлекчәләре буенча каралган бүленгән акчалар 6 нчы кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

4) 9 статьяда:

2024 елга «5,0» санын «0,0» санына алмаштырырга;

2025 елга «5,0» санын «0,0» санына алмаштырырга;

2026 елга «5,0» санын «0,0» санына алмаштырырга;

4) 10 статьяда:

1 пунктта «587 964,1» саннарын «609 097,3» саннарына алмаштырырга;

9 нчы кушымтаның «2024 елга җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә муниципаль учреждениеләрне карап тоту буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә җирлекләр бюджетларыннан район бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 1 нче таблицасында үзгәрешләр кертелә торган өлешен бәян итәргә.

5) 12 статьяда муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме:

2024 елга «36 089,1» санын «45 180,0» санына алмаштырырга.

6) 13 статьяда:

11 нче кушымтаның «2024 елга өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен җирлекләр бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар күләме» таблицасында үзгәрешләр кертелә торган өлешен бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдщ тотуны икътисади үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка һәм туризм мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

3. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

Комиссия рәисе урынбасары — Р.Л. Исланов